Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының утыз беренче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

12 апрель, 2023 ел № 219

2022 елда Татарстан Республикасында һәм Питрәч муниципаль районында кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен саклау турында

Татарстан Республикасы Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең «2022 елда Татарстан Республикасында һәм Питрәч муниципаль районында кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен саклау турында» Питрәч муниципаль районында җәмәгать ярдәмчесе мәгълүматын тыңлап **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. 2022 елдагы Татарстан Республикасында һәм Питрәч муниципаль районында кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен саклау турында мәгълүматны игътибарга алырга.
2. Питрәч муниципаль районы милкенең барлык рәвешләрендәге учреждениеләр, оешмалар һәм предприятиеләр җитәкчеләренә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчесе мәгълүматын исәпкә алуны, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен бозу очракларын булдырмау чараларын күрүне, халыкны хокукый агартуга юнәлдерелгән чараларны активрак үткәрүне тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарны Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов